КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 май г.Казань № 430

Татарстан Республикасы территориясендә җир мәйданының бер сотыеннан шәхси ярдәмче хуҗа-лыкта алынган җимешләрне һәм продукцияне реализацияләүдән чиста керемнең кыйммәти чагылыштагы айлык нормативы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә җир мәйданының бер сотыеннан шәхси ярдәмче хуҗалыкта алынган җимешләрне һәм продукцияне реализацияләүдән чиста керемнең кыйммәти чагылыштагы айлык нормативын 364 сум күләмендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир мәйданының бер сотыеннан шәхси ярдәмче хуҗалыкта алынган җимешләрне һәм продукцияне реализацияләүдән чиста керемнең кыйммәти чагылыштагы айлык нормативы турында» 2011 ел, 5 июль, 538 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җир мәйданының бер сотыеннан шәхси ярдәмче хуҗалыкта алынган җимешләрне һәм продукцияне реализацияләүдән чиста керемнең кыйммәти чагылыштагы айлык нормативын хисаплап чыгару тәртибен раслау турында»;

2 нче пункт үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы территориясендә җир мәйданының бер сотыеннан шәхси ярдәмче хуҗалыкта алынган җимешләрне һәм продукцияне реализацияләүдән чиста керемнең кыйммәти чагылыштагы айлык нормативы турында» 2019 ел, 15 май, 400 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин